ГЛАВА СОКОЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.38, с. Соколка,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422181

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОКОЛКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Мәктәп ур., 38 нче йорт, Соколка авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422181

тел.(факс): (85563) 3-82-05; e-mail: Sokol.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар
«22» октябрь 2020 ел.

Постановление
№ 13

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлегенең Соколка авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге” Уставының 23 статьясы нигезендә карар бирәм :

1. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Соколка авылы , Мәктәб урамы, 3А адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында 2020 елның 12 нче ноябрь сәгать 10.00 Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлегенең Соколка авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын **беренче этабын** билгеләргә кушымта нигезендә №1.
2. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Соколка авылы , Мәктәб урамы, 3А адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында 2020 елның 13 нче ноябрь сәгать 10.00 Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлегенең Соколка авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын **икенче этабын** билгеләргә кушымта нигезендә
№ 2.

1. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2021 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме :

- урамнарны яктырту объектларына хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт, махсус җиһазларны сатып алу һәм алыштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Соколка авылында юлларга вак таш җәю (сатып алу, таш ташу, килешү буенча эш өчен түләү);
- Соколка бистәләрендә юлларны кардан чистарту.

« ӘЙЕ»　　　　　　　　　　　　«ЮК».

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге башкарма комитетына Соколка авылында гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә .

3. Әлеге карарны кабул иткәннән соң 3 көн эчендә муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Соколка авыл җирлеге башлыгы:　　　　　　　　А.Г. Рахимзянов